ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4; 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Әлеге Закон милкендә, хуҗалыгында яисә файдалануында музей әйберләре һәм музей тупланмалары булган Татарстан Республикасында гамәлдә булган һәм яңадан төзелә торган барлык музейларга һәм башка оешмаларга, шулай ук физик затларга кагыла.»;

2) 9 статьяда:
а) 2 өлештә «башка оешмаларга» сүзләреннән соң «(дини оешмаларны да кертеп)» сүзләрен өстәргә;
б) 3 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына бәйле исәпкә кую документларында музей әйберләре һәм музей тупланмалары турында белешмәләр булган әлеге музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының фактта булуын һәм физик сакланышын, шулай ук мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органында музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына реставрация эшләрен үткәрү хокукына мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы

тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аттестация узган затлар тарафыннан мондый эшләр үткәрүне;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 01 март
№ 8-ТРЗ